وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# ДИН вә Мәгыйшәт

№13 (110). 11 ноябрь 2011 / 15-зөлхиҗҗә-1432

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Рәфыйк МӨХӘММӘТШИН: "Мөселманнарның фиркаләре дә, фракцияләре дә юк" ▷2◁



Социологик сораштыру: татар яшьләренең 90 проценты дингә ышана ▷3◁



Корбан-марафон: Казан – Яңа Кырлай – Казан ▷4◁

## Мөхтәсибәт ЯҢАЛЫКЛАРЫ

### ТУКАЙ

5 ноябрь көнне Иректаң авылында мәчет ачу тантанасы булып үтте. Бәйрәмгә бик күп кунаклар килгән иде.

Мәчет шушы авылның эшмәкәр егетләре, авыл халкы тарафыннан төзелгән. Татарстан картасында 83 ел элек барлыкка килгән авыл тарихында бу әле беренче мәчет. Шулай итеп, Иректаң авылы халкы Корбан бәйрәменә зур бүләк алды.

### КАЗАН

6 ноябрь көнне Казандагы 46 мәчеттә илле меңнән артык кеше бәйрәм намазы укыды. Көн салкын, җилле булуга да карамастан, мәчетләргә сыймаган күп кенә кеше бәйрәм вәгазен урамда тыңлады.

Казан шәһәре Башкарма комитетының Телләрне үстерү һәм иҗтимагый берләшмәләр белән элемтәләр бүлеге башлыгы Ирек Арсланов хәбәр итүенчә, башкалабызда яшәүчеләр мәчетләр аша барлыгы биш мең чамасы сарык һәм йөзләп сыерга заказ биреп, корбан чалган. Шуның кадәр үк мал-туарны эшмәкәрләр мәчет яннарына алып килеп саткан.

### ӘЛМӘТ

Әлмәт районындагы "Җәмигъ" газетасының яңа саны дөнья күрде. Әлеге басманы гамәлгә куючылар - Әлмәт шәһәре һәм Әлмәт районы мөхтәсибәте. "Җәмигъ"ның әлеге саны Корбан гаетенә багышланган, шуңа да беренче биттә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, республикабыз мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз, Әлмәт муниципаль районы башлыгы Ришат Әбүбакиров һәм Әлмәт имам-мөхтәсибе Рафикъ хәзрәт Миңнәхмәтовның бәйрәм котлаулары бирелгән. Газетаның баш мөхәррире - Р.Миңнәхмәтов.

### БӨГЕЛМӘ

6 ноябрьдә Бөгелмә Җәмигъ мәчетендәге гает намазына тугыз йөзләп кеше килгән. Мәчет янында йөз сарык чалынган.

- Бәйрәмнән соң мәчет ишегалдында төшке аш оештырылды. Бирегә килүчеләр тәм-томнар авыз итү бәхетенә иреште, - дип хәбәр итте Бөгелмә мөхтәсибәтенең дәгъват һәм мәгълүмат бүлеге җитәкчесе Хәбир хәзрәт Ханов.

### АЗНАКАЙ

- Мөхтәсибәт күләмендәге мохтаҗларның һәрберсенә - барысы йөздән артык кешегә - 1-1,5 килограммлап ит тараттык. Фәкыйрьләрне җыеп, 150 кешегә өстәл әзерләдек. Азнакайга спонсорлар ике мөгезле эре терлек биргән иде. Мөхтәсибәт каршында дүрт мең сумнан сарык сату оештырдык. Ике йөзләп сарык чалынды. Корбанлыкларның барысы да үзебезнең районныкы иде. Малларны чалу өчен мәчет ишегалдында махсус урын булдырган идек, - дип белдерде Азнакай шәһәре һәм Азнакай районы имам-мөхтәсибе Әмирҗан хәзрәт Якупов.

Шунысын да искәртик: Азнакай шәһәрендә дини укулар да тулы көченә дәвам итә. Авылларга килгәндә исә, Уразай, Урсай, Тымытык, Мәнәвез, Балтач, Туйкә авыллары мәчетендә дәресләр үтә. "Кичке сәгать биштән кичке сәгать сигезгә кадәр укытабыз, дәресләр атнасына өч көн уза", - диде Әмирҗан хәзрәт.

## КАМИЛЛЕКНЕҢ ЧИГЕ ЮК

Мөселманнар сан буенча дөньяда икенче урында тора. Билгеле булганча, бу сан 1,5 миллиард тирәсе, дип тә билгеләп үтелә. Ислам әһелләре дөньяның 130 илендә яши. Кырыкка якын илдә мөселманнар күпчелек булып тора, алар мәдәни, сәяси, икътисади процессларга зур йогынты ясый. Хәзерге вакытта ислам дөньясының гаять зур рухи потенциалы һәм көч-куәте күзәтелә. Бүтән диннәрдән аермалы буларак, ислам дине үзенчәлекле һәм катлаулы яңарыш процессы кичерә, мөселманнарның саны зур темплар белән арта бара. Мөмкинлекләр дә җитәрлек, ләкин без аларның барысын да кулланабызмы икән соң? Уртача гади кеше, гомеренең тиешле потенциалының 10 проценттан да азрак өлешен үти, дип фаразлый белгечләр. Мисал өчен, ХХ гасырның атаклы галиме Альберт Эйнштейн булган потенциалының унбиш процентын гына файдаланган. Баш мие эшчәнлеген тикшерүче галимнәр, гади кеше үз мөмкинлекләренең ике процентын гына куллана, дигән нәтиҗәгә килгән. Әлеге күрсәткечләрне арттыру өчен без нәрсәләр эшлибез соң? Кызганыч, үз өстебездә эшләүгә зур тырышлык куймыйбыз. Ислам дине буенча яши башлау белән, еш кына пассив тормышка күчәбез. Шәригать кушканнарны үтибез, Аллаһы Тәгаләнең ярлыкавын һәм изге теләкләребезнең чынга ашуын сорыйбыз һәм еш кына: "Ни язылган булса, шул булыр", дип, тормышның үз көенә генә баруын карап тора башлыйбыз. Уйлап карасаң, тормыш бара, дөнья кайный, ә без - күзәтүчеләр сыйфатында. Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә адәм балаларын җир йөзенә тормыш барышын күзәтүче буларак кына яралтканмыни соң?


Ислам динендә булган кеше шәригать кануннарын үтәү белән генә чикләнергә тиеш түгел, ә бәлки, булган белемнәрен тормышның файдалы һәм тиешле урыннарында кулланып, җәмгыять үсешенә йогынты ясап, динне тормыш кануны, тормыш кагыйдәсе итеп алып, үзе өчен генә түгел, тирә-юньдәгеләргә дә файда китерү өстендә бил бөгәргә тиештер. Кызганыч ки, бүгенге көндә мөселманнар бу әйберне еш кына исләреннән чыгара. Ләкин, өммәтебездә дини һәм дөньяви тормышка бүленү булырга тиеш түгел, ислам дине - яшәешнең барлык өлкәләрен дә үз эченә алган хәлдә, мөселман кешесен ике дөнья өчен дә камиллеккә ирешүен тәэмин итүче дин ул.

Кайберәүләр, дингә килүгә үк, еш кына фани дөньяны кире кага башлаган була, бер чиктән икенче чиккә сикерә башлый. Гаҗәеп бит: шуннан соң без мөселман илләренең артта калу сәбәпләрен эзли башлыйбыз. Шуңа күрә дә мөселман өммәте үсеше, алгарышы өчен нинди игелекле гамәлләр кылдым, нинди файдалы гыйлемнәр алдым, үзем генә түгел, диннең камилләшүенә нинди өлеш керттем, дип уйларга кирәк. Әлбәттә, бөтен кешегә дә зур потенциал бирелмәгән. Шул ук вакытта, күбебез гади генә тоелган сәләтләргә дә ия бит. Ләкин без шул булган талантыбызны үстерү өстендә эшлибезме соң?.. Һәрхәлдә, һәрберебез үз мөмкинлекләрен бер генә процентка булса да файдалы якка борып җибәрә алса, бу өммәтебез өчен 1500000000 процентка файдалы үсеш булачак...

*Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ*

*Илфат ФӘЙЗРАХМАНОВ:*

## "Аулак урында гына хайван суярга рөхсәт итәр идем"



***- Кызганыч, быел корбан чалырга өлгерә алмадым. Мосафир булдым, дип акланасым килми: әлеге дини йоланы үти алмыйча калуымның төп сәбәбе - корбанлык турында алдан сөйләшеп куярга җитешмәвемдә.***

Мин, гадәттә, корбан чалуны авылда үти идем. Быел, көне җитәрәк кенә авылдашларыма шалтыратып карадым, юк, нихәл итәсең, сарык табылмады. Казан мәчетләрендә дә корбанлык турында алдан килешеп куярга кирәк икән. Шәһәрдән тапкан булсам да, аны кеше тулы машинада авылга алып кайтып йөрүләре, аннан соң суючысын табуы - шулай ук җиңел эш түгел. Хәер, без акланырга оста. Гафу үтенәм, быел уйламадым. Ә узган ел корбан гаете вакытында больницада идем. Шунысын да уйлап куйдым әле: узган елны миңа Корбан бәйрәме алдыннан операция ясаганнар иде, шул чакта да корбан чалырга җитешкән идем...

Шунысы гаҗәп: узган елны корбан итен кая куярга белмичә аптырап беткән идек, быел без чалмагангамы, күчтәнәч итеп корбан ите китерүчеләр дә аз булды. Мөгаен, әнием исән-сау булганда аңа дип китергәннәрдер инде. Өстәвенә, корбан итенә аерым игътибар булырга тиеш дип саныйм: аны теләсә кая таушалдырып йөртергә ярамый. Без гаиләбез белән моңа җаваплы карыйбыз: суыткычта аны аерым урынга куябыз, бүтән итләр белән (калганнары да хәләл булса да) бутамаска тырышабыз. Ә болай мин һәрдаим "Казан нуры" мәчетенә йөрим. (Тик, төзелеш сәбәпле, мәчет әйләнә-тирәсендә казу эшләре алып барылганлыктан, машина белән килүчеләргә бераз кыенлыклар туды.)

Казанда быел теләсә кайда корбан чалырга рөхсәт булмады. Әлбәттә, бу шулай булырга тиеш, тәртип кирәк. Санитария таләбе үтәлү-үтәлмәү бер читтә торсын... Әмма, шәхсән үзем, яше-каршы, балалар каршында, кеше күзе алдында хайван сую процессы баруны бөтенләй аңламыйм. Ә бит бу европалыларда алай түгел. Әби-бабаларыбыз да елның бу вакытында каз өмәләре уздырган. Җир туңдыргач, эре терлек суйган. Ә бит алар мондый эшне аулак урында, кеше күрми торган җирдә башкарган. Малтуарның каны, биологик калдыклары туфрак белән күмеп куелган. Безнең әле күп нәрсәгә өйрәнәсебез бар. Мисал өчен, Төркиядә теләсә кем корбан чала алмый, бу эшне башкарырга алынам дигән кеше анда махсус курсларда укып, имтихан тапшырып, сертификат алырга тиеш. Ә бездә мал суючыларның хәтта медкнижкалары да юк, һәрхәлдә, аны таләп итәргә кирәк, дигән сүзнең булганы да юк. Югыйсә, бүгенге көндә медкнижкасыз кибеткә азык-төлек ташучы булып та урнашып булмый, ә корбан чалучы булып йөреп була. Мәчетләргә корбан чалучылар туплаганда шунысына да игътибар итсәләр иде. Минем "санитария таләбе" дигән төшенчәне катлауландырасым килми, әмма шулай да бер сарык чалган өчен биш йөз сумга кадәр акча сорыйлар икән, барысы да наят булырга тиеш. Акча түлисе килмәгән кеше авылына алып кайтып чалсын! Үз күзе белән күреп килсен: анда да бит теләсә кайда чалмыйлар.

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

## Корбан бәйрәмен ничек уздырдыгыз?

**ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең "Зәкят" хәйрия фондыннан Альбина САБИРОВА:**

Благотворительный Фонд Закят

- Алабуга шәһәренең ит комбинатында унике сыер чалынды. Корбан ите дини уку йортларына бирелде, мохтаҗларга өләшенде.

10 ноябрь көнне Казан педагогика көллиятендә студентлар һәм мөгаллимнәр катнашында йөз кешелек зур корбан ашы уздырылды. Мәҗлес барышында "Зәкят" хәйрия фонды җитәкчесе Рөстәм хәзрәт Ясәвиев яшьләргә вәгазь-нәсихәт сөйләде, изге теләкләрен җиткерде.

Шулай ук, 11 ноябрьдә "Зәкят" хәйрия фонды Ислам динен кабул итүнең 1000 еллыгы исемендәге мәдрәсә белән берлектә мәҗлес уздырырга ниятли. Әлеге корбан ашына мәдрәсәдә укучы шәкертләр, мөгаллимнәр, өлкән яшьтәге хәзрәтләр, күрмәүче инвалидлар чакырылган. Чараны уздыруда зур ярдәм иткәне өчен ҖЧҖ - "Ак-барс" кошчылык комплексына "Зәкят" фонды зур рәхмәтен белдерә.

Бу чаралар, һичшиксез, Корбан бәйрәме традицияләрен саклап калуда һәм яшьләребезгә рухи тәрбия бирүдә зур өлеш кертер.



**Мансур МОРТАЗИН, "Шәһри Казан" газетасының баш мөхәррире:**

- 6 нчы ноябрь көнне иртән иртүк мәчеткә бардым. Мин үзебезнең өй янындагы "Казан нуры" мәчетенә йөрим. Гает укып кайткач, гаиләм белән утырып чәй эчтек. Якшәмбе көнне корбан чалу мөмкинлегебез булмады, әлеге гамәлне 7 нче ноябрьдә башкардык. Моннан соң ел саен корбан чалырга ниятләп торам.

*Нияз САБИРҖАНОВ сорашты*

*Рәфыйк МӨХӘММӘТШИН:*

# "Мөселманнарның фиркаләре дә, фракцияләре дә юк"

***4 декабрьдә илебездә РФ Дәүләт Думасына сайлаулар узачак. Белгәнебезчә, әлеге сайлауларда барлыгы җиде партия катнашачак: "Единая Россия", "ЛДПР", "КПРФ", "Справедливая Россия", "Патриоты России", "Яблоко", "Правое дело", дип яза Татарстан Республикасының intertat.ru электрон газетасы.***

**Россия - күпмилләтле һәм күпдинле ил. Мөселманнар, төрле статистика чыганаклары китергән мәгълүматларга караганда, илебез халкының 10-15 процентын тәшкил итә, бу исә 20 миллионлап кеше, дигән сүз. Димәк, сайлауларда катнашучыларның шактый өлеше мөселманнар. Ә инде аларның дини карашлары әлеге сайлаулар өчен мөһимме? Мөселманнар шушы җиде партиянең кайсысы өчен тавыш бирер?**

Әлеге сорауларга җавап табу, шул ук вакытта, сәясәттә дини карашның урыны һәм мөселманнарның төрле партияләргә мөнәсәбәтен ачыклау ниятеннән Россия ислам университеты ректоры, сәясәт фәннәре докторы, профессор Рәфыйк Мөхәммәтшин белән әңгәмә кордык.

**- Рәфыйк әфәнде, Россиядә мөселманнарның сайлауларга йогынтысы нинди?**

- Россия Конституциясе буенча, партияләр дини һәм милли карашларга корылырга тиеш түгел. Шуңа күрә дә, бүгенге көндә сайлауларда конфессиональ юнәлешне билгеләү шактый авыр. Мөселманнарның фиркаләре дә, Дәүләт Думасында үз фракцияләре дә юк. Шунлыктан, сайлаулар барышында мөселманнарның позициясе нинди, дигән сорауга җавап бирү кыен. Әлбәттә, һәрбер фирка мөселманнар белән үзенчә эшли. Ә менә "ЛДПР"ны алсак, аларны исә мөселманнар тавышын җыю кызыксындырмый. Ул "Россия - руслар өчен" дигән лозунг белән рус милләтчеләре һәм башка шушы юнәлештәге көчләр аша үзенең 10-15 процент тавышын җыя алыр. Бүгенге көндә бу партия, рус милләтчелеге көчәю сәбәпле, "Россия - руслар өчен" дигән лозунг чыгарды, элек ул юк иде.

**- Димәк, фиркаләр сәясәте рухи хисләрдән башка гына корыла, дип әйтү барыбер чынбарлыкка туры килеп бетми?**

- Менә бу сайлауларның, бәлки, үзенчәлеге дә шулдыр - милли һәм дини чагылышлар күренә башлады. Ә башка партияләргә килгәндә, алар, Россия дөньяви дәүләт булгач, толерант булырга тиеш, дип, дини-милли факторларны күпертми һәм бу дөрес тә.



**- Ә кайсы фиркаләр мөселманнарның тавышларына күбрәк өмет итә ала, дип саныйсыз?**

- Мөселманнарда гына түгел, башка дингә инанучылар арасында да тавышлар төрле юнәлештә бүленәчәк, дип әйтергә мөмкин. Гадәттән тыш хәл кебек күренсә дә, коммунистлар өчен өлкән яшьтәге мөселманнар арасында тавыш бирүчеләр шактый булыр, дип уйлыйм. Чөнки хәзер инде коммунистлар дигән сүз - ул большевизм түгел. Программаларына карасак, алар Европаның социаль демократларына якын. "Коммунистлар - атеистлар, шуңа күрә аларга мөселманнар тавыш бирергә тиеш микән?", - дигән мәсьәләне күтәрү хәзер бик үк дөрес булмас иде.

**- Дөньяви дәүләттә үз фиркаләре дә булмаган төрле дин тотучыларның, шул исәптән мөселманнарның дини ихтыяҗларын кем кайгыртырга тиеш соң?**

- Ихтыяҗларны канәгатьләндерү ул - бүгенге көндә илдә конфессиональ сәясәт булдыру, дигән сүз. Конфессиональ сәясәт - бөтен диннәргә дә тигез карау. Әлбәттә, Россиядә тигез караш бармы дигәндә, аны тәгаен генә әйтү җиңел түгел. Ә менә Татарстанны аерып караганда, бездә андый сәясәт алып барыла, дип әйтә алабыз. Мәсәлән, Мәскәүне алыйк. Бүген анда өч мәчет эшли, ике миллионнан артык мөселман яши. Корбан бәйрәмендә 70 меңнән алып 100 меңгә кадәр кеше урамга җыела. Корбан чалу өчен урын кирәк. Шул ук вакытта православ чиркәве "Адым саен чиркәү" программасын тормышка ашырырга җыена, ике йөзләп чиркәү салабыз, диләр. Хәзер анда тугыз йөзләп храм бар. Чагыштыру өчен Европаны алыйк. Лондонда ике миллионлап мөселман яши, бөтен Англиягә дүрт йөзләп мәчет бар. Парижда мәчетләр саны әллә кайчан инде йөздән артып китте. Мәскәү - мөселманнарның проблемаларын көзге кебек чагылдыра. Төбәкләрдә дә бар ул проблема, мисал өчен, аларның да кайберләрендә мөселманнарга мәчет салырга җир бирмиләр. "Бердәм Россия" кебек күп тавыш җыярга омтылган фиркаләргә дин вәкилләрен борчыган хәлләргә күбрәк игътибар итү кирәк булачак. Бу - мәҗбүри эш, чөнки мөселманнар Россиядә артканнан арта бара. Статистика буенча, XXI гасырның 50 нче елларына алар 25-30 процентка артыр, дип фаразлана. Бүгеннән үк инде дини проблемаларны инкарь итү мөмкин түгел.

**- Ничек уйлыйсыз, киләчәктә, әйтик, Татарстаннан берәр дин әһеле депутат булып сайланырмы?**

- Бүгенге көндә РФ Дәүләт Думасында мөселман фракцияләре юк. Шуңа күрә дә дин әһеле турыдан-туры депутат була алмый. Мөселман фракциясе булмаса да, Думада мөселман зыялылары эшләргә тиеш. Мөселманнарның мәнфәгатьләрен эчтән аңлап, аларның проблемаларының чишү юлларын күрсәтүче шәхесләр, әлбәттә, кирәк.

***Айзирәк ГӘРӘЕВА***


# Дөнья кинлегендә – дин

***1-3 ноябрь көннәрендә Казан университетында "Мультимәдәни дөньяда ислам дине" дип исемләнгән форум эшләде. Форумны КФУның Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара мөнәсәбәтләр институты Мәскәү шәһәрендәге "Мәрҗани" фонды белән берлектә уздырды.***

Мондый төр чара Татарстан башкаласында беренче тапкыр үтүгә карамастан, ул үзенә бик зур аудитория җәлеп итте. Биредә Россия төбәкләреннән генә түгел, хәтта Үзбәкстан, Казакъстан, Төркия, Грузия, Иран, Малайзия, Пакьстан, Босния һәм Герцеговинадан ике йөзләп алдынгы белгеч җыелды. Форумны уздыру өчен Казан шәһәрен сайлау да юкка түгел, чөнки Казан университеты мөселман халыклары күпләп яшәгән Көнчыгышны өйрәнү үзәге булып тора.

Форумга җыелган кунакларны сәламләп, Казан (Идел буе) федераль университетының Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара мөнәсәбәтләр институты директоры Линар Латыйпов: "Республикабызда ислам динен өйрәнүнең нигезе ныклы. Форум кысаларында исламны өйрәнүчеләр "түгәрәк өстәл"ләр, секцион утырышлар вакытында төрле актуаль проблемалар һәм сорауларны күтәрә алачак", - диде.

Татарстанның Дәүләт Советы узган гасырның 90 нчы еллары башында беренчеләрдән булып дини оешмалар һәм сүз ирегенә бәйле закон кабул итте. "Без бик күп дини оешмалар белән хезмәттәшлек итәбез, бергә төрле чаралар үткәрәбез. Казанда мондый чаралар уздырылу безнең тәҗрибәнең дөньякүләм кызыклы булуы турында сөйли. Җөмһүриятебез төрле конфессия вәкилләренең дус һәм бердәм яшәве белән башкаларга үрнәк булып тора", - диде ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев.




ТР Президенты ярдәмчесе Тимур Акулов үз чыгышында ислам диненә мөнәсәбәтнең бөтен җирдә бер дәрәҗәдә булмавын, кайдадыр диннең террорчылык белән тәңгәлләшүенә басым ясады, һәм: "Мондый форумнар ярдәмендә бүгенге көн проблемаларын билгеләп, аларны чишү юлларын күрсәтсәк иде", - дип белдерде.

Пленар утырышны Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгыш кульъязмалар институты директорының фән буенча урынбасары Станислав Прозоров ачып җибәрде. Аның "Ислам динен фәнни өйрәнү: проблемалар һәм перспективалар" дип исемләнгән доклады катнашучыларда зур кызыксыну уятты. Шулай ук Гуманитар һәм культурологик тикшеренүләр институты профессоры Сәидә Җавада Мири (Иран Республикасының Тәһран шәһәре), Халыкара ислам университеты хезмәткәре Эльмира Әхмәтова (Малайзиянең Куала-Лумпур шәһәре), Россия хокук академиясенең Казан филиалы профессоры Айдар Хәбетдинов чыгышлары да игътибарны җәлеп итте.

1-2 ноябрь көнне "Россиядә ислам динен өйрәнүнең актуаль мәсьәләләре", "Суфичылык теориясе һәм практикасы", "Мөселман булмаган илләрдә мөселман кабиләләре", "Мөселман дөньясы сәнгате" кебек темаларга секцион утырышлар һәм "түгәрәк өстәл"ләр эшләде, - дип яза "Darelfənyn" газетасы.

***Динара ӘХМӘТОВА***

*Илфат ФӘЙЗРАХМАНОВ:*

# "Аулак урында гына хайван суярга рөхсәт итәр идем"

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

Авылда кеше бер-берсен яхшы белгәч, бу эшне дә пөхтә, чиста, оста, җиренә җиткереп башкарган кешегә әйтергә тырышалар.

Гомумән алганда, ислам дине әдәбе буенча, теләсә кайда мал чалырга ярамый (аеруча, бу эшне агым су, кое-чишмә, зират яннарында үтәүдән сак булырга кирәк). Мин, мәсәлән, үзем мал чалганны карап тормаска тырышам, хайванны бик тә җәллим. Кайчагында телевизор экраннарыннан, газета битләреннән мал-туар каны коелу мизгелен күрсәтәләр икән, моңа, әлбәттә, без - журналистлар гына гаепле. Бигрәк тә моннан карагруһ, ультрашовинистик темага эшли торган массакүләм мәгълүмат чаралары бик оста файдалана. Без аларга ирек бирмәскә тиеш. Менә шул хакыйкатьне аңлату җитми безгә һәм корбан чалу процессын балалар, әлеге күренешне йөрәге, күңеле аша уздыра алмаган кешеләр күрмәслек итеп эшләргә акылыбыз, көчебез, тәрбиябез җитми дип әйтер идем. Шул ук корбан чалуны безнең көннәрдә "вәхшилек" дип күрсәтергә омтылыш ясаучылар да бар. Мин бу фикерне шушы атнада чыккан "Безнең гәҗит"тә дә бирергә тырыштым. Интернетта корбан бәйрәме темасына багышланган форумнарда утырсаң чәчләр үрә тора. Без үзебез дә үзебезнең газеталарыбызда кулга кул тотынышып яшәүче башка кардәшләребезгә Корбан бәйрәменең кайбер нечкәлекләрен аңлата алмыйбыз. Минем үземнең дә кайбер чиста рус кешесенең базарларда хәләл ит сорап йөргәннәренә шаһит булганым бар. "Хәләл" сүзе бүгенге көндә бар халык өчен дә "чиста" сүзе белән аваздаш. Ә нәрсә, безнең Корбан бәйрәме көннәрендә чалган малларыбыз хәләл түгелмени? Димәк, без гаеттә дә мөселман булмаганнарга хәләл, чиста ит таратуыбызны, бәйрәм көннәрендә дә пакьлек-сафлыкка тагын да якынаюыбызны аңлатырга тиешбез. Ә бит, уйлап карасаң, ит комбинатларында малны кот очарлык итеп үтерәләр, минем, хәтта, укыганым бар, бүгенге көндә кешеләрнең кансызлана баруы - шушы ит комбинатлары аркасында. Анда чират көтеп торучы мал "коллегасының" үлгәнен карап торып, курку инстинкты ит күзәгенә дә кереп сеңеп кала икән. Шушы итне ашаган кеше яисә җанвар буыннан-буынга кырыслана, вәхшиләнә бара, дип укыганым бар һәм мин моңа ышанам. Чөнки ислам дине кануннары буенча малны тыныч кына, кычкырмыйча, сыйпап кына, сиздермичә генә, иркәләп кенә чалырга кирәк. Мал чалганда хайваннар бер-берсен күрергә тиеш түгел. Хәтта бу кагыйдә тавык, каз кебек кошлар суйганда да үтәлергә тиеш.

Мин беркайчан да - газетада да, телевидениедә эшләгән вакытта да - мал сую процессын тасвирламадым, фотога да төшермәдем. Мин экраннардан корбан чалуны күрсәтү яклы түгел. Малны чалып җибәргән вакытны махсус күрсәтәләр бит. Бу хәлне тыярга тиешләр. Чөнки канга кеше күнегә башлый. Ул экранда да, рәсемдә дә күренергә тиеш түгел. Малны бугазлаган вакытны күрсәтү - мәгънәсезлек. Гомумән алганда, мин мөселманнарга аулак урында гына хайван суярга киңәш итәр идем.

***Нияз САБИРҖАНОВ язып алды***
***Фото business-gazeta сайтыннан алынды***

# Республикабызда "Сабыйга-2" акциясе дәвам итә

**18 ноябрьгә кадәр "Яңа гасыр" радиосы Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте белән берлектә "Сабыйга-2" акциясен уздыра.**

Әлеге чара кысаларында Казанның Киров районында урнашкан Балалар инфекцион хастаханәсенә ярдәм күрсәтеләчәк. Биредә әниләре ташлап киткән яңа туган сабыйларга "ватные палочки", памперслар, яңа туган сабыйларга яраклы киемнәр кирәк.

Балаларга ярдәм итәргә теләүчеләр түбәндәге адрес буенча мөрәҗәгать итә ала: 420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт (ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең хәйрия бүлеге). Белешмәләр өчен телефон: +7 (843) 236-52-12, 89872639889 (Гөлнара Садыйкова).

Ятимнәргә карата мөнәсәбәткә бәйле рәвештә Аллаһ илчесе (с.г.в.): "Кем дә кем ятим баланы үзенә тәрбиягә ала, аның хокукларын саклый һәм башыннан ягымлы итеп сыйпый икән, шул кешегә Аллаһы Тәгалә, бу ятимнең башында күпме чәче бар, шул хәтле савап бирәчәк, бу ятимнең башында күпме чәче бар, шул хәтле гөнаһларын кичерәчәк һәм бу ятимнең башында күпме чәче бар, шул хәтле дәрәҗәләр бүләк итәчәк", - дип әйткән ("Мәҗмугатуль-бәян").

***DUMRT.RU***

# ХИКМӘТЛЕ РУХИ ОСТАЗ

**Әй, бу күңел!.. Әллә яшьлек галәмәте - хис кичерешләрем үз касәсенә сыймыйча, ургылып ташып тора кебек... Бар тойгыларым, фикер-уйлануларым, бәгыремне телгәләп, пошаманга сала, һаман мине борчый, йөдәтә... Ә дөньяда - гөрләп торган ямьле җәй. Нигә соң бу якты кояш, чиста, зәңгәр күк, саф һавалы, җиләк-җимешле, матур чәчәкле табигать манзарасы бүген шулай уйландыра, сагайта? Хәзрәтнең вәгазе сәбәп моңа, җәмәгать.**



Габделхак хәзрәт Саматовның бик гыйбрәтле, тирән мәгънәле вәгазен мин бүген радиодан тыңладым. Кеше гомерен ел фасыллары белән чагыштырды ул. "<...> Балачак - ул яз кебек. Алсу таң аткан, агачлар бөреләнгән, чәчәкләрнең дөньяга яңа күренгән чагын шатлыклы һәм ваемсыз, эчкерсез, самими балачак чоры белән тиңләп була. Яшьлек исә гөрләп торучы күңелле җәй кебек. Ә инде картлык... анысы көз: гүзәл чәчәкләр шиңеп, яфраклар саргаеп, болытлар куерган чак булса да, бу вакыт, гадәттә, унышны барлауга, нәтиҗә ясауга багышлана.

Ә алда - салкын кыш... Адәм баласының гомер көзе, ягъни картлык чоры да чамасыз түгел шул. Табигать ап-ак карга төренеп йокыга талган кебек, кеше затын да, вакыты җиткәч, ак кәфенгә төреп гомере "кышы"на - ахирәткә озаталар. Уйлап карагыз әле сез: яз көне берни чәчмәгән, җәен эшкәртмәгән, көзен дә басуда эшләмәгән кеше кышка кергәндә нинди хәлдә кала? Шулай ук балачагында динне өйрәнмәгән, яшьлек чорын гыйбадәтсез үткәргән, олыгаеп барган көннәрендә дә үзенең Раббысы белән кирәкле мөгамәлә булдырмаган кеше ахирәткә ничек күчәр, Яратучысы каршында ничек җавап тотар?" - диде Г.Саматов.

Менә шуның турында фикер йөртеп, уйга чумдым да инде мин, кардәшләрем. Шактый күп вакыт заяга узган сыман: ул укылмаган намазлар, тотылмаган уразалар, үзләштермәгән гыйлемнәр, белем булмау сәбәпле эшләнгән хаталар... У-ух! Хәзер миңа нишләргә? Кая барырга? Шунда Аллаһның рәхмәте белән башыма бер фикер килде: "Мәрҗани" мәчетенә барып, Габделхак хәзрәт белән күрешеп, үземне борчыган мәсьәләләр буенча сөйләшергә, киңәш-нәсихәт алырга кирәк. Анда минем инде берничә тапкыр булганым бар, шәт, Иншә Аллаһ, бу юлы да хәзрәт борып чыгармас, сорауларыма ачыклык кертер...

* * *

Менә, ниһаять, мин Казанның рухият күрке булып танылган "Мәрҗани" мәчете янында. Узган гасырның туксанынчы еллар башында бу мәчеткә күбрәк өлкән яшьтәге кешеләр йөри иде. Намазга килүче бабайлар гына түгел, гыйбадәтханәнең диварлары, ишек-тәрәзәләре дә, идәнгә җәелгән кызыл келәмнәре дә нининдидер үзенчәлекле, күңелгә хуш килә торган борынгылыкны чагылдыра иде. Ул чорда яшәгән татар зыялылары, дин галимнәре рухы тоела иде. Мәчетнең фарыз залына керүгә Шиһабетдин Мәрҗани яки Каюм Насыйри хәзрәтләре намаз укып тора сыман, дип карап торган чакларым да булгалады бугай. Ул вакыттагы мәчетнең мөәзине Идрис абый чалма-чапанын киеп куйса, үзе дә Мәрҗанигә охшап китә иде. Мәчет хезмәткәре Шәйхулла абый исә үз-үзен тотышы, кыяфәте белән ничектер Каюм Насыйрины хәтерләтте.

XIX гасыр галимнәрен очратмасам да, "Мәрҗани" мәчетендә XX гасыр хикмәт иясе, рухи остазым Габделхак хәзрәт Саматовның даими булуы да минем өчен зур шатлык, аң-белем алу өчен менә дигән форсат иде. Бу юлы да өйлә намазын укыганнан соң, мин хәзрәттән рөхсәт сорап аның бүлмәсе янына юнәлдем. Ишек төбендә яшь егет белән кыз басып тора иде. Никах укытырга дип килүләре икән.

- Шаһитләрегез бармы? - дигән сорауга, егет, бу тәртипне белмәвен, ә кәләшнең рус кызы булганлыгын җиткерде. Шулай да кыз татарча бераз аңлый икән. Хәзрәт һәм яшьләр белән мин дә бүлмәгә үттем. Утырышкач, Габделхак хәзрәт дога кылды да егет белән кызга никах тәртибен аңлатырга кереште:

- Беренчедән, никах мөселманнарга укыла. Икегез дә Аллаһы Тәгаләнең барлыгына-берлегенә иман китергән хәлдә, мөэмин-мөэминә булып тормыш юлыгызны башлап җибәрү зарур. "Ләә иләәһә иллә Аллаһү, Мүхәммәдүр расүлүллаһ" кәлимәсен тел белән генә әйтеп калмыйча, күңел белән кабул итәргә кирәк. Синең, егет, мәчеткә килүеңнән дә дингә уңай мөнәсәбәтеңне аңлап була, ләкин кәләшең безнең милләттән түгел бит, бу хакта ни диярсез?

Егет бер хәзрәткә, бер кызына карап ала да, тартыныбрак, әкрен тавыш белән әйтә:

- Яратам мин аны, абый. Ул да мине ярата... Яратмаса, монда ияреп килмәс иде.

- Яле, әйдә үзеннән сорыйк. Ислам динен кабул итеп, яңа тормыш башларга ризамы син, сеңлем? Белеп, аңлап кияүгә чыгасыңмы?

Кыз югалып калмый һәм ышаныч белдергән кыяфәт белән җавап бирә:

- Я выхожу замуж. Это означает всю жизнь идти за мужем: куда он - туда и я. Его выбор - это и мой выбор. Поэтому я согласна.

Габделхак хәзрәт мәһәр, шаһитләр һәм башка никах шартларын аңлатып, килү көнен билгеләгәннән соң, яшьләр чыгып китә. Ишек ябылгач исә имам канәгатьсезлеген белдереп, болай ди:

- Ярыйсы гына матур пар булып күренә болар, шулай да гомерлек тормыш юлдашың итеп үз милләтеңдәге кешене сайлау хәерлерәктер, чөнки өйдә балалар ана телен үзләштереп үсә. Аларны дини һәм милли рухта тәрбиялисе була бит, шунысы мөһим…

- Хәзрәт, гаилә тормышы тигез, бәхетле булсын өчен, әлбәттә, бер диндә, бер милләттә булу мөһим, әмма тышкы кыяфәт, матурлык, мәхәббәт дигән нәрсәләр дә бар бит әле. Бу егетнең кыз курчак кебек чибәр бит, үзең дә сизмәстән гашыйк булырсың…

Габделхак хәзрәт күзләрен кысып елмаеп куя да, философларча сорый:

- Ә нәрсә соң ул матурлык? Бу - бик четерекле мәсьәлә. Миңа калса, чын матурлык - ул күңел матурлыгы. Яшьләр бит хәзер еш кына тышкы күренешне өстен итеп яр сайлый. Әмма чын мәхәббәт аңа нигезләнә алмый. Ир-хатын бер-берсен яратырга гына түгел, хөрмәт итәргә дә тиеш. Тормыш иптәшеңә карата кайгыртучан булу, үзеңә җайсызрак булса да, аның ихтыяҗларын өстен күрү, кирәк вакытта сабыр булып кала белү - ир-хатын арасындагы мәхәббәтне раслаучы да, ныгытып торучы да сыйфатлардыр.

Әле кичә генә бер хатын килеп, елыйелый үз зарын сөйләгән иде. "Яшьрәк чакта бик чибәр идем, - ди. - Ләкин тормыш иптәшемнән уңмадым: кул күтәрде, эчте, җитмәсә өстән йөрде. Аерылыштык. Хәзер менә кызым да язмышымны кабатлый кебек. Ул да бик чибәр... Нигә матур хатын-кызлар шундый бәхетсез икән?" - дип сораган иде ул. Мин әйтәм: "Менә кара: аланда төрле-төрле чәчәкләр үсә. Арасында аеруча матурлары, күз явын алырдай җете төсләләре бар. Аларга бик күп кеше кызыга. Шул кешеләр арасында тыйнак, тәүфыйклылары да, тупас, азгын, усаллары да очрый. Шушы матур чәчәкне кем алданрак өзә? Әйе, усал, әрсезалабай булганы. Ул аны өзә дә, ташлый, бүтәне янына йөгерә.

***Ришат хәзрәт КУРАМШИН,***
***Кукмара мәдрәсәсе директоры***

*(Ахыры киләсе санда.)*

# СОЦИОЛОГИК СОРАШТЫРУ: татар яшьләренең 90 проценты дингә ышана

***1 ноябрь көнне Казан (Идел буе) федераль университетында узган "Мультимәдәни дөньяда ислам дине" дип аталган I Халыкара фәнни форум барышында социология фәннәре кандидаты, КФУдагы журналистика һәм социология факультетының социология кафедрасы доценты Гүзәл Гүзәлбаева: "Татар яшьләренең 90 проценты дингә ышана, шул дингә ышанучы яшьләрнең 92 проценты үзләрен мөселман, дип саный", - диде.***

Аның чыгышы "Татар яшьләренең үз-үзләрен ислам дине белән идентификацияләүләре (2009-2011 еллардагы социологик сораштыру нәтиҗәләре буенча)" дип аталган иде.

Мондый төрдәге сораштырулар 2009-2011 елларда Татарстанның төрле районнары һәм шәһәрләрендә яшәүче 16-28 яшьлек татар яшьләре арасында үткәрелгән, дип яза islam-portal.ru сайты.

Гүзәл Гүзәлбаеваның күзәтүләре буенча, тикшеренүләр түбәндәге кызыклы фактларны ачыклый.

Россия халкының дингә мөнәсәбәте турында сүз барганда, социологлар, гадәттә, өлкәннәрнең яшь буынга, хатын-кызларның ир-атларга, югары белеме булмаганнарның укымышлы булучыларга караганда динлерәк булуы турында әйтә.

Татар халкына килгәндә исә, нәтиҗәләр бөтенләй башкачарак. Гыйбадәт һәм дини йолалар үтәү буенча татарлар арасында яшьләрнең өлкәннәргә, хәтта урта буын вәкилләренә караганда да динлерәк булуы, ә белем дәрәҗәсе һәм социаль халәт татар яшьләренең дин тотуга артык зур йогынтысы булмау турында сөйли.

2011 елгы тикшеренү нәтиҗәләре буенча, татар яшьләренең 90 проценты үзләренең дингә ышануы турында җиткергән һәм бары тик өч проценты гына Аллаһы Тәгаләгә ышанмавын әйткән.

Социолог сүзләренә караганда, соңгы өч ел эчендә татар яшьләре арасында дин таралу буенча артык зур үзгәрешләр күзәтелми һәм бу идеологик карашлар белән бәйле түгел. Бәлки, 90 процент - ул инде максимум чиктер?!

Шул 90 процент яшьләр арасында гыйбадәтләрен калдырмыйча үтәүчеләр һәм дингә ышанып та, ислам диненең барлык фарыз гамәлләрен башкармый йөрүчеләр дә җитәрлек. Кызларның биш проценты яулыктан йөри, егетләрнең шулай ук биш проценты хатыннарының хиҗаптан йөрүен таләп итә. Тагын бер факт: татар яшьләренең 5 проценты намаз укый.

Сораштыруда катнашкан яшьләрнең яртысы һәрдаим мәчеткә йөри; 4,7 проценты мәчет бусагасын атнасына бер генә тапкыр атлап керсә, калганнары исә мәчеткә даими рәвештә йөрми. Соңгысы турында сүз алып барганда, тагын бер моментны истә тотарга кирәк: кызларга җомга намазына мәчеткә йөрү мәҗбүри түгел.




Татар яшьләренең 16,5 проценты дуңгыз ите ашамый, исерткеч эчемлекләр кулланмый, ә 27,4 проценты - хәрам рызыклар ашамаска тырыша.

"Булачак хәләл җефетегезнең мөселман булуы сезнең өчен мөһимме?" - дигән сорауга 42,7 процент халык: "Бик мөһим", - дип җавап бирсә, 41,2 проценты - "Бик үк мөһим түгел", ә 11,6 проценты - "Бер дә мөһим түгел", - дип җавап биргән. Шуның белән бергә, яшьләрнең 10 проценты өчен хәләл җефетенең үз милләт кешесе (татар) булуыннан бигрәк, мөселман булуы мөһимрәк, ә 44,7 процентына исә, киресенчә, беренче чиратта, татар булуы мөһим. Татар яшьләренең 51 проценты "ЗАГС"та теркәлү узу белән беррәттән, никах укытуның да мөһим булуын искәртә, ә 3,2 проценты - никах укыту гына да җитә, дип саный.

"Танышыгыз булган татар кешесе динен алыштырса, сезнең аңа мөнәсәбәт-карашыгыз ничек булачак?" - дигән сорауга 35 процент кеше: "Гаеп итеп караячакмын", - дип, ә 7,5 проценты - "Андый кеше белән аралашуны чикләячәкмен", - дип җавап биргән.

Яшьләрнең 16,9 проценты татар кешесе белән мөселман кешесе арасында билгеле бер уртаклыклар күрә, алар өчен "татар кешесе" - ул инде мөселман, дигән сүз.

***Гөлназ БӘДРЕТДИН***
***әзерләде***

# КОРБАН-МАРАФОН: КАЗАН – ЯҢА КЫРЛАЙ – КАЗАН

***Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең яшьләр бүлеге нигезендә эшләүче "Алтын урта" җәмгыяте гает бәйрәме уңаеннан "Корбан-марафон" үткәрде.***



Бер төркем яшьләр - "Алтын урта" активистлары җыелышып, корбан чалды, Г.Тукайның балачагы узган җирләрдә - Яңа Кырлайга кайтып, корбан ашы үткәрде. Сарык итеннән пешерелгән пылаудан авыз иткәннән соң, мөселман яшьләре Тукай музеен, булачак шагыйрь яшәгән Сәгъди абзый йортын карады һәм бәләкәй Апуш укыган мәдрәсә урынындагы мәчеттә намаз укыды.

Бер ай дәвамында "Алтын урта" яшьләре мөмкинлеге булган кешеләрдән мохтаҗ гаиләләр өчен ярдәм, хәйрия чаралары кабул иткән иде. Яшьләр кием-салым, китаплар, канцелярия товарлары белән берләттән, мохтаҗ гаиләләргә корбан ите дә тапшырырга исәпли. Бу эшне бер атна эчендә тәмамларга ниятлиләр.

"Алтын урта" мондый чараларны "Даһилар эзеннән" проекты кысаларында даими оештырып, активистлар белән тарихи урыннар буенча киләчәк тә экскурсияләр оештырмакчы.

"Ә активистлар сафына теләгән һәркем баса ала", - ди оештыручылар.

***Ләйсән ФӘТХЕТДИНОВА фотосы***

# Солтан кунагы - Нургали ахун

***Татарлар арасында мөселманнарның соңгы хәлифе солтан Габделхәмид II белән күрешкән, аның белән якыннан аралашкан шәхесләр аз була. Шуларның берсе - ахун, дәмулла Нургали Хәсән әл-Буави (Хәсәнов Нургали) (1852-1919). Ул 1917 елгы революциягә кадәр танылган дин һәм җәмәгать эшлеклесе, заманына күрә билгеле кешеләренең берсе була. Аның тормыш юлы гаять тә кызыклы.***

Бүгенге көнгә хәтле сакланган тарихи мәгълүматлар буенча, ул 1852 елның 8 ноябрендә Татарстанның хәзерге Апас районындагы Морзалар авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч белемне әтисе Хәсән хәзрәт мәдрәсәсендә ала. Аннары Казандагы IV Җәмигъ мәчете (хәзерге "Зәңгәр мәчет") каршындагы Исхаковлар мәдрәсәсендә укый. 26 яшендә Бохара шәһәренә китеп, "Мир - Араб" югары мөселман дини мәдрәсәсен тамамлый һәм зур гыйльми дәрәҗәләргә ирешә.

1886 елның 12 декаберендә Нургали хәзрәт Буаның I мәхәллә мәчетенә имам-хатыйб һәм "Нурия" мәдрәсәсенә мөдәррис итеп билгеләнә. Кыска гына вакыт эчендә ул үзенең киңкырлы эшчәнлеген җәелдереп җибәрә.



Мәдрәсәсенең даны тирә якларга да тарала. Анда Сембер (Ульяновск), Казан губернияләреннән генә түгел, илебезнең ерак өлкәләреннән дә, мисал өчен, хәтта Әстерхан губерниясеннән дә шәкертләр килеп, дини белем ала. 1913 елны гына да биредә унике укытучы җитәкчелегендә өч йөздән артык шәкерт укый. Үзенең киңкырлы эшчәнлеге өчен аңа Оренбург мөселманнарының Дини идарәсе тарафыннан ахун дәрәҗәсе бирелә.

Нургали хәзрәт күп сәяхәт итә, шул исәптән, хаҗ сәфәренә дә бара. Күп кенә шәһәрләрдә туктап, галимнәр белән күрешә. Истамбулда мөселманнар хәлифе солтан Габделхәмид II тарафыннан чакырылып, изге Рамазан аен аның сараенда үткәрә. Анда илнең төрле сәясәтчеләре, галимнәре, җәмәгать эшлекләре белән аралаша. Хәлиф белән динебезнең кыйммәтле ядкарьләрен, рәсүлебезнең (с.г.в.) хыркасын зиярат итә.

Заманында аның фикъһ (хокук белеме) һәм мантыйк (логика) буенча дәреслекләре популяр була. Шулай ук ул, ишан буларак, күп кенә мөридләр дә тәрбияли.

Нургали әл-Буави 1919 елның 19 маенда вафат була. Буа шәһәренең татар зиратында җирләнә. Аның эшчәнлеген ике улы - Гыясетдин (1889-1922) һәм Ибраһим (1895-194?) дәвам иттерә.

***Рәшид МАЛИКОВ, ТР Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты аспиранты***

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *Шимбә* | 12.11.2011 | 6:41 | 8:11 | 13:02 | 15:29 | 16:42 | 18:12 |
| *Якшәмбе* | 13.11.2011 | 6:43 | 8:13 | 13:02 | 15:28 | 16:41 | 18:11 |
| *Дүшәмбе* | 14.11.2011 | 6:45 | 8:15 | 13:02 | 15:27 | 16:39 | 18:09 |
| *Сишәмбе* | 15.11.2011 | 6:47 | 8:17 | 13:02 | 15:26 | 16:37 | 18:07 |
| *Чәршәмбе* | 16.11.2011 | 6:49 | 8:19 | 13:02 | 15:25 | 16:35 | 18:05 |
| *Пәнҗешәмбе* | 17.11.2011 | 6:51 | 8:21 | 13:02 | 15:23 | 16:34 | 18:04 |
| *Җомга* | 18.11.2011 | 6:53 | 8:23 | 13:02 | 15:23 | 16:32 | 18:02 |

# Сәламәт тәндә – сәламәт акыл



***Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте соңгы елларда сәламәтлек саклау, спорт һәм физик тәрбия мәсьәләренә зур игътибар бирә башлады. Мөселман яшьләре арасында шәһәр, республикакүләм, Россия беренчелеге буенча ярышлар ел дәвамында булып тора. Бу - үзеңне физик яктан күрсәтү, сыгылмалылык, көч, чыдамлылык кебек сыйфатлар тәрбияләү өчен зур мөмкинлек. Ярышлар һәрвакытта да Коръән аятьләре укып башлана, вакытында намаз укыла.***

Вахитов районындагы 51 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе стадионында мөселман яшьләре арасында футбол, турникта тартылу, дартс буенча шәһәр беренчелеге ярышлары булып узды. Аны ТР мөселманнары Диния нәзарәте оештырды. Футбол уенында сигез команда катнашты. Болар - Россия ислам университеты, Казан ислам колледжы (КИК), Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге һәм "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе, "Мәрҗани", "Солтан", "Ризван", "Әниләр" мәчете командалары. Футбол уенында РИУ командасы чемпион калды, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе - II, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә шәкерләре III урын яулады. Россия ислам университетының I курс студенты Рамазан Мотыйгуллин "Иң яхшы уенчы" дип табылды.

Турникта тартылу буенча да көч сынашу ярышлары булып узды. РИУның I курс студенты Артур Сабиров иң югары нәтиҗә күрсәткечләренә иреште. Казан ислам колледжының III курс студенты Гомәр Гамадаев - II, "Мәрҗани" мәчетеннән Фирзәр Җәләлов III урынны яулады. Җиңүчеләргә Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте әзерләгән истәлекле бүләкләр һәм дипломнар тапшырылды.

**Рафаэль МИФТАХОВ, мөгаллим, ярышларны оештыручы**

# Мәйданчык

*(Балалар өчен башваткыч)*



***Буш шакмаклар урынында булырга тиешле рәсемнәрне ясап, исемнәрен яз. Алар турында син ниләр беләсең?***

Әлеге биремне безгә "Тылсымлы куллар" редакциясе тәкъдим итте. Әлеге басманы үзегездә булдырасыгыз килсә, 89172372642 телефонына шалтыратыгыз. 2012 елдан әлеге журналда балалар өчен дини тематикага кагылышлы кызыклы материаллар урын алачак.

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №13 (110) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-513.

**Газета бушлай таратыла.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 10 ноябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**